"АРЗАНГАРАК ФАТИР ТАБЫП БИРӘБЕЗ, ДИП АЛДАДЫЛАР"



» 4

"ҮЗ СҮЗЕМ, ЯЗМЫШЫМ БАР!"



» 8

"БҮГЕН ЯШӘРГӘ КИРӘК"



» 12

"КУНАКЛАРНЫ 40 МИНУТ БАЯН БЕЛӘН ҖЫРЛАТТЫК"



» 14

"ҺӘР ТАМЧЫ КҮКРӘК СӨТЕ ӨЧЕН АНАГА САВАП ЯЗЫЛА"



» 22

25 ИЮНЬ, 2020 №25 (512)

# ИРЕК МӘЙДАНЫ

12+

## Ә СЕЗ ИШЕТТЕГЕЗМЕ?

- **Чәршәмбе, 1 июльдә РФ Конституциясенә төзәтмәләр кертү буенча Гомумроссия тавыш бирүе уза.** Ул — эшләми торган ял көне.
- Россия Үзәк банкы **ставканы 4,5 % итеп төшерде.**
- Быел "Татспиртпром"ның **тауар сатуы 17 %ка кимегән.**
- Роскомнадзор **"Telegram"га чикләүләрне бетерде.**
- Татарстанда **5 шифаханә ачылды.**
- Кыргызстанның элекке президенты **Алмазбәк Атамбаев 11,2 елга ирегеннән мәхрүм ителде.** Барлык дәүләт бүләкләрен алдылар, милкен конфискацияләделәр.
- Минзәлә районында "Opel" машинасы **кабаннар көтүен бәрдергән, 7 хайван үлгән.**
- Татарстанда 80 медицина хезмәткәре **коронавирус йоктырган.**
- АКШта КПСС Үзәк комитетының беренче секретаре **Никита Хрущевның улы Сергей Хрущев үлде, аңа 84 яшь иде.** Ул техник фәннәр докторы, Ленин премиясе лауреаты, Социалистик Хезмәт Герое булды. 1991 елда АКШка күчеп китте.
- Согуд Гарәбстаны, коронавирус сәбәпле, быел **чит илләрдән килгән хаҗиларны кабул итмәячәк.**





© Станислав Шахлеин/МИА-Россия Сегодня

**Бу арада умартачылар зур борчу белән яши. Кайбер районнарда басуларны агулап, бал кортлары үлә башлаган. "Узган ел басуларны агулау нәтиҗәсендә 20-25 мең баш умарта харап булды. Бу — республикадагы умарталарның 10 %ы дигән сүз", — ди умартачылар.**

Быел беренче шомлы хәбәр Тәтеш районыннан килде.

— Умарталыгымда 60 баш умарта бар иде, — ди Ивановка авылы умартачысы Виктор Лакеев. — 16 июньнән рапс басуларын агуларга керештеләр. Шуннан соң 4-5 көн эчендә барлык кортлар диярлек кырылып бетте. Беренче көннәрдә алай күп үлмәде, аннары тотынды: бөтен оялар алдында бал кортлары өелеп үлеп ята. Җаныкайларым кайтып җиткәннәр дә үләннәр. Авыл хуҗалыгы оешмалары басу агуларга 3 көн кала умартачыларга хәбәр итәргә тиеш. Ә болар көндез хәбәр итте дә кич белән агуларга керешкәннәр. Алдан әйтсәләр, бал кортларын ябып тотарга мөмкин иде. Әле бит исән калганнары да әрәм булмас дип әйтә алмыйбыз, көн саен иртән оя алдында үлгән кортлар күрәбез.

(Ахыры 10 нчы биттә.)

## КЫЗЫК ФИКЕР



— Эшлибез, чабабыз, шул вакытта күңел тынычлыгын югалтырга мөмкинбез. Аны кайдан алып була? Шөкер итәргә кирәктер. Канәгатьләнү хисе булса, тормыш җиңелрәк бара, миңа калса... Дога уку, Аллаһы Тәгаләгә ышану да, аңа буйсыну да күңел тынычлыгы бирә.

**Айдар ГАЛИМОВ, җырчы.**
*("Ватаным Татарстан" газетасыннан)*



— Чын татарча — "ата-ананы кайгырту", ә хәзер кая карама "ата-ана турында кайгырта" рәвеше. "Станок артында", "руль артында", "табын артында" калькалары теләсә кайсы даирәдә "үз" булып бетте. Дөресе — станокта, рульдә, табында.

**Илдар НИЗАМОВ, филология фәннәре докторы.** *(Matbugat.ru)*



— Зур хыялларымның берсе — бәхетле гаилә кору. Бер өйләнгәч, яратып, хөрмәт итеп яшисе килә. Өйгә кайтырга теләмичә йөрерлек булмасын. Мин балаларны да бик яратам. Аларның аурасы, самимилеге, гадилеге бөтен авыруга дәва.

**Илназ ГАРИПОВ, җырчы.**
*("Шәһри Казан" газетасыннан)*

## САН

**● Диспансеризация узганыгыз бармы?** ВЦИОМ үткәргән сораштыруда катнашучыларның **35 %ы — өч ел, 21 %ы 4-5 ел элек, 18 %ы быел сәламәтлеген тикшерткән. 20 % кешенең бер тапкыр да диспансеризация узганы юк, 6 %ы җавап бирергә кыенсынган.**

## КЫЗМАГЫЗ!

Люция ӘБЛИЕВА



© karkhem/stock.adobe.com

*Кызмагыз... Кыздырмагыз...*
*Җир шары булсын рәтле.*
*Марска барып яшәрлек*
*Кайсыгызның бар рәте?*

*Кызмагыз... Кыздырмагыз...*
*Җир шары бәлык түгел.*
*Җиңел булмас бушатырга,*
*Хәсрәткә тулса күңел.*

*Ишетмәгәнгә кабатлыйм:*
*Кызмагыз... Кыздырмагыз...*
*Кычытмаган җирне кашып,*
*Чирне узындырмагыз...*

# “ҮЗ СҮЗЕМ, ЯЗМЫШЫМ БАР!”

**Фәүзия Бәйрәмованы белмәгән татар юктыр. 1991 елда республика бәйсезлеге өчен көрәшкән, үзе артыннан меңләгән татарны ияртә кешеләрнең берсе ул. Бу язмамда Фәүзия Бәйрәмованы нәкъ менә хатын-кыз буларак ачасым килде.**



**— Фәүзия апа, сезне французларның Жанна д'Аркы, татарларның Сөембикәсе белән чагыштыралар. Бу хакта нәрсә уйлыйсыз? Мондый чагыштыру урынлымы?**

— Жанна д'Арк та, Сөембикә-ханбикә дә — милли азатлык көрәшчеләре, үз халкы тарафыннан дошманга тотып бирелгән фаҗигале шәхесләр, корбаннар. Мине алар белән чагыштырганда, фаҗигале язмышларын түгел, милли азатлык өчен көрәшүне күздә тоталардыр, мөгаен. Чөнки хатын-кыз соңгы чиктә генә яу башына баса, халкына азатлык даулап, мәйданга чыга.

Мине дә мәйданга заман, милләт үзе этеп чыгарды, чөнки ул вакытта башкача мөмкин түгел иде. Ир-атлар булмаганнан түгел, ул чорда милли хәрәкәттә, халык арасында гаярь ир-егетләр күп иде. Әмма милләт язмышында иң кискен, иң кирәк вакытта алар хәлиткеч гамәл кылырга, соңгы сүзне әйтергә ашыкмады. Һаман нидер көттеләр. Ә хатын-кыз йөрәге белән тоя, нәселенә, милләтенә килеп яткан бәла-казаны җан күзәнәкләре белән сизенә! Мондый чакта ничек дәшмичә калырга мөмкин?! Шуңа күрә 1991 елда ачлык мәйданына чыктым һәм анда ахыргача булдым. Халык депутаты буларак, Югары Советта һәм мәйданнарда иң кискен сүзләрне миңа башлап әйтергә туры килде. Әлбәттә, болар өчен судларны да, утларны да күп күрдем... Халык, бәлки, менә шуларны күздә тотып, мине Жанна д'Арк, Сөембикә белән чагыштырадыр, әмма мин — Фәүзия Бәйрәмова! Үз йөзем, үз сүзем, үз язмышым бар, Аллага шөкер!







**— Тарихта эз калдыру өчен хатын-кыз нинди сыйфатларга ия булырга тиеш?**

— Иң башта Кеше, Шәхес, Талант булырга кирәк! Бу — ир-атка да, хатын-кызга да кагыла. Ә гүзәл затка шушыларны икегә тапкырларга, ягъни тарихта үз эзен калдыру өчен аңа ике йөрәк, ике баш кирәк! Бал кортыдай тырышлык, ана арысландай гайрәт, гасырлар аша күрерлек зирәклек, гамәл һәм сүзләрдә ихласлык, сабырлык, Аллаһ ризалыгы өчен яшәү һәм милләтең файдасына эшләү... Бу — бер көндә барлыкка килгән сыйфат һәм гамәлләр түгел. Кеше моңа гомере буе килә, шушы максатка эшли.

Миндә беркайчан да курку хисе юк иде! Ә нәрсәдән куркырга?! Үз милләтеңнең хокукларын яклап мәйданга чыгу — ул бит гаделлек өчен көрәш! Ә гаделлек өчен көрәшкән кеше бернәрсәдән курыкмый! Татар халкының телле, динле, дәүләтле булырга хакы бар дип санадым. Соңгы гасырларда авыр, фаҗигале юллар үтеп тә исән калган милләт бит ул! Шунысын да әйтим: милләт хокукларын яклап мәйданга чыкканда, инде җәмгыятьтә үз урыным булган, өлгергән шәхес идем — СССР Язучылар берлеге әгъзасы, Татарстан китап нәшриятында редактор, Татарстан Югары Советы депутаты.

**— Мөселман хатын-кызларын күбрәк өйдә гаилә учагын саклаучы, тыйнак зат итеп күзаллыйбыз. Ә сездә аларга хас булмаган туры сүзлелек, ирләр белән янәшә бару кебек сыйфатлар бар...**

— Шәригатьтә ир-атка да, хатын-кызга да таләп бер — иманлы, гадел, ихлас бул, колга әверелмә! Заманында мөслимәләр ир-атлар белән бергә яуга барган, корал тотып, илләрен һәм җирләрен саклаганнар. Сөембикә-ханбикә дә 1549-1550 елларда Казанны ана арысландай яклаган, ул чакта Явыз Иван Казанны ала алмаган. 1551 елда ханбикәне Мәскәүгә тоткын итеп җибәргәч кенә, икенче е[illegible] Казанны килеп басып алганнар. Татар тарихы менә шундый аянычлы һәм гыйбрәтле ул...



**— Казан театр училищесының режиссерлык бүлеген тәмамлаган Фәүзия Бәйрәмова ни өчен татар театрына хезмәт итмәде?**

— Укуны 1971 елда тәмамладым. Ул бер генә чыгарылыш булды, аннан аны Казан мәдәният институтында ачтылар. Бу училищеда укуымның сәбәбе — Саба районы газетасында хәбәрче булып эшләгәндә үк сценарий, драмалар яза идем. Шуңа күрә режиссурага укырга кердем. Аны тәмамлагач, Казан телевидениесендә режиссер ярдәмчесе һәм ассистенты булдым.

1975 елның ахырында гаиләбез белән Монголиягә эшкә китәргә туры килде. Дөрес, өч елдан соң аннан кайтып, Казан телевидениесендә тагын бераз эшләдем, тапшырулар өчен сценарий яздым. Аннан “Казан утлары” журналына корректор булып урнаштым. Беренче әсәрләремне дә шунда эшләгәндә яздым. 1983 елда Казан дәүләт университетына читтән торып укырга кердем. Татар теле һәм әдәбияты бүлегендә белем алсам да, дипломны тарих буенча якладым. Театр училищесында укуның да файдасы тиде — дистәгә якын драма әсәрем бар, кайберләре сәхнәдә куелды.

**— Иҗатыгызга килик әле... 1983 елда “Болын” дигән беренче күләмле әсәрегез басылып чыкканнан соң, каләм ияләренең игътибарын җәлеп итәсез. Бәхәс купкач, сезне Әмирхан Еники, Гариф Ахунов, Аяз Гыйләҗев кебек аксакаллар яклап, фатыйха биреп, уңай фикерләрен**



1991 ел. Казанның Ирек мәйданында ачлык тоту.



Хәтер көне мизгеле.

**язып чыга. Бу — зур мәртәбә, моны ничек кабул иттегез?**

— "Казан утлары" журналындагы әдәби мохит иҗатыма уңай тәэсир итте. 1983 елның сентябрь санында журналда "Болын" повестем басылды һәм шактый шаушу кузгатты. Кемдер мактады, кайберәүләр гаеп табарга тырышты. Әсәрнең баш каһарманын сәерлектә гаепләделәр. "Үзе турында язган. Бу — аның бердәнбер һәм соңгы әсәре, башка яза алмаячак", — диделәр. Хәтта мәртәбәле кешеләр: "Болын" сөрелергә тиеш!" — дип газеталарга яздылар. Ә ул әсәр кеше күңеле турында, болын аның символы гына иде... Менә шуны иң беренче булып Әмирхан Еники күрде. Әсәрне укыганда елаган, диделәр. "Бу бала нәрсә язганын аңладымы икән?" — дигән.

1986 елда "Болын" Татарстан китап нәшриятында китап булып басылды, аңа кереш сүзне Әмирхан Еники язды. Әйе, ул вакытта мине [illegible]пат язучылар — Әмирхан Еники, Аяз Гыйләҗев, Гариф Ахунов, тәнкыйтьче Фәрваз Миңнуллин ачыктан-ачык яклап чыкты. Нурихан Фәттах, Шәриф Хөсәенов фатыйхаларын бирде.

**— Фәүзия Бәйрәмова ир хатыны, балалар анасы буларак нинди?**

— Кешенең тормышы да, иҗатындагы кебек, төрле чорлардан тора. Яшьрәк чакта тәҗрибә җитми, шуңа күрә шактый ялгышлар да җибәрелә. Яши-яши күп нәрсәне аңлыйсың, үткәндәге хаталардан гыйбрәт аласың, шәхси тормышыңның ничек булуы үзеңнән дә торуына төшенәсең. Җаваплылыкны тулысынча үз өстеңә аласың. Минем дә ялгышлар булды, соңрак булса да аларны төзәтеп, үз юлыма чыктым. Хәзер, Аллага шөкер, тормышымнан канәгать.

Һәр татар анасы кебек, мин дә яшьлегемдә балаларыма бөтен көчемне, сәламәтлегемне бирдем. Аларның укуларын, әдәбиятны, тарихны, фәнне һәм динне белүләрен теләдем. Кызым Зөлфия башта Кипрда инглиз телендә халыкара хокук факультетында укыды. Аннан Әнкарада аспирантура тәмамлады. Үз белгечлеге буенча Америкада белем алды һәм эшләде. Милләтемә хезмәт итәм дип, 2004 елда Казанга кайтты. Хәзер дә монда яши. Улым Альберт-Сөләйман Чаллыда татар гимназиясен тәмамлады, аннан Малайзиядә укыды. 2000 еллар башында улыбыз монда кайтты, Ислам университетында белем алды. Хәзер магистратура тәмамлый. Кызым кебек, улым да күп телләр белә, гарәп, төрек, инглиз телләреннән татарчага һәм русчага фәнни, дини хезмәтләр тәрҗемә итә.

Ирем Җәмил — юрист, төп таянычым, ярдәмчем. Киләсе елда Чаллыда яши башлаганыма 30 ел була. Шушы вакыт эчендә ул иҗат итәргә бөтен шартларны тудырды. Тормышны ирем алып барды, әллә ни байлыгыбыз булмаса да, үзебезгә җитте, Аллага шөкер! Чаллыга өч китап авторы буларак килгән идем, хәзер илленчесе чыгарга тора, шуларның барысын да диярлек ирем бастырды. Мин язам гына, аларны китап итеп чыгару, акчасын, кешесен, урынын табу, соңыннан аларны урнаштыру — ирем өстендә. Ай саен диярлек Әгерҗе аша Себергә яки Уралга озату һәм каршы алуны да ул башкара. Эштән кайткач, токмачлы аш, бәлеш, кыстыбый пешереп, иремне сыйлау — минем өстә... Ул — туры сүзле, куштанлыкны, мескенлекне белми торган булдыклы ир. Күп фикеребез уртак. Каршылык булса, артык куертмыйбыз, әмма һәркем үз фикерендә кала. Күңел ачу мәҗлесенә, кунакка йөрмибез, күп аралашуны, ыгы-зыгыны яратмыйбыз — өйдә укыйбыз да язабыз. Китапханәбез зур, анда ун меңгә якын китап бар. Безгә мондый яшәү рәвеше ошый, Аллаһым тигезлектән аермасын!

**— Кызыгызга үзегез үткән юлны теләр идегезме?**

— Бу дөньяда һәркемнең үз юлы. Зөлфиябез бик белемле, динебезне хөрмәт итә, милләтне ярата. Ләкин безне чагыштырып булмый... Кызым Гарвард профессорларыннан сәясәт белемен өйрәнде, ә без авыл болыннарыннан килеп, мәйданнарда зур сәясәткә чыктык. Иҗат мәсьәләсендә дә мине кабатлау авыррак булачак, чөнки безне саф татар мохите — авыл тәрбияләде, ә ул — шәһәрдә үскән бала. Дөрес, кызым татарча бик яхшы белә, үзен тәрбияли, күп укый, әмма язу — бөтенләй башка нәрсә! Хәер, анысын вакыт күрсәтер!

Бу тормышта үз биеклегемә, Аллаһ ярдәме белән, язмыш әзерләгән баскычлардан күтәрелдем. Журналистика, әдәбият, сәясәт, дин һәм фән — барысына да үз чираты белән килдем. Балаларымны да үз язмыш баскычлары көтә дип уйлыйм. Аларга калдырырлык матди байлыгым юк, ә тау-тау китапларым — бар... Фәүзия Бәйрәмова дигән исемем кала. Милләт яшәгәндә хезмәтләрем дә онытылмас, иншаллаһ!

**Руфия РӘХМӘТУЛЛИНА.**